КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 13 гыйнвар г.Казань № 8

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының иң төзек торак пункты» республика конкурсы турында» 2006 ел, 25 сентябрь, 482 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 22 февраль, 63 нче; 2011 ел, 24 сентябрь, 790 нчы, 2018 ел, 7 май, 329 нчы, 2020 ел, 06 апрель, 257 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «Татарстан Республикасының иң төзек торак пункты» республика конкурсы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктның унҗиденче абзацында «иң яхшы предприятие, учреждение, башка оешма» сүзләрен «иң яхшы оешма» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктның өченче абзацында «предприятиеләр, учреждениеләр, башкалар» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү өлкәсендә конкуренцияне үстерү чаралары турында» 2010 ел, 9 апрель, 251 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 27 июнь, 441 нче; 2015 ел, 19 май, 357 нче; 2017 ел, 7 август, 560 нчы; 2019 ел, 2 сентябрь, 757 нче, 2020 ел, 27 ноябрь, 1067 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «06.10.2003» саннарын «2003 елның 6 октябре» сүзләренә алмаштырырга, «25.12.2008» саннарын «2008 елның 25 декабре» сүзләренә, «04.05.2006» саннарын «2006 елның 4 мае» сүзләренә, «06.05.2011 № 354» саннарын «Күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда урыннар милекчеләренә һәм кулланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү турында» 2011 ел, 6 май, 354 нче» сүзләренә, «13.08.2006 № 491» саннарын «2006 елның 13 августында «2006 елның 13.08.491» саннарын «Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тоту кагыйдәләрен һәм

Торак урынны карап тоту өчен тиешле сыйфаттагы күпфатирлы йортта хезмәт күрсәткән һәм (яисә) билгеләнгән дәвамлылыктан артып киткән күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тоту һәм ремонтлау эшләрен башкарган очракта түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында» 2006 ел, 13 август, 491 нче» сүзләренә, «06.02.2006» саннарын «2006 елның 6 феврале» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карарга 3 нче кушымтада:

1.5 пунктта:

«Халыкка күрсәтелгән торак һәм коммуналь хезмәтләр сыйфатын арттыру һәм түләү күләменең нигезлелеге чаралары турында» 2010 ел, 09 апрель, 250 нче» сүзләрен төшереп калдырырга;

«гражданнар, үз вакытында» сүзләреннән соң «һәм тулы күләмдә» сүзләрен өстәргә;

2.6 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

2.8 пунктка «2013 ел, 15 май, 416 нчы» сүзләреннән соң «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибе турында» сүзләрен өстәргә;

12 бүлектә «Ф.И.Ат.ис.» сүзләрен «(Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда)» сүзләренә алмаштырырга;

бүлмә милекчесе белән күпфатирлы йорт белән идарә итү шартнамәсенә 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

бүлмә милекчесе белән күпфатирлы йорт белән идарә итү шартнамәсенә 2 нче кушымтада:

1 пунктта:

2 нче графада «СНиП 2.04.02-84*» сүзләрен «СП 31.13330.2021» сүзләренә алмаштырырга;

татар текстында 3 нче графага «2011 ел, 6 май, 354 нче» сүзләренә кадәр «Күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда урыннар милекчеләренә һәм кулланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү турында» сүзләрен өстәргә;

2 пунктның 1 графасында «СанПиН 2.1.4.1074-01» сүзләрен «СанПиН 1.2.3685-21» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктның 2 графасында «СанПиН 2.1.4.2496-09» сүзләрен «СанПиН 1.2.3685-21» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктның 1 графасында «СанПиН 2.1.4.2496-09» сүзләрен «СанПиН 1.2.3685-21» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктның 1 графасында «СанПиН 2.1.4.2496-09» сүзләрен «СанПиН 1.2.3685-21» сүзләренә алмаштырырга;

12 пунктның 1 графасында «ГОСТ 5542-87» сүзләрен «ГОСТ 5542-2014» сүзләренә алмаштырырга;

15 пунктның 1 графасында «ГОСТ Р 51617-2000» сүзләрен «ГОСТ Р 51617-2014» сүзләренә алмаштырырга;

«[5]» астөшермәсендә «ГОСТ Р 51617-2000» сүзләрен «ГОСТ Р 51617-2014» сүзләренә алмаштырырга;

«[6]» астөшермәсенең икенче абзацында «ГОСТ 30494-96» сүзләрен «ГОСТ 30494-2011» сүзләренә алмаштырырга;

бүлмә милекчесе белән күпфатирлы йорт белән идарә итү шартнамәсенә 3 нче кушымтада:

преамбулада «һәм Россия Федерациясе Юстиция министрлыгында 2003 елның 15 октябрендә теркәлгән (5176 номерлы теркәү номеры)» сүзләрен төшереп калдырырга, «ВСН 58-88б «Торак биналарны, коммуналь һәм социаль-мәдәни билгеләнештәге объектларны реконструкцияләүне, ремонтлауны һәм аларга техник хезмәт күрсәтүне оештыру һәм уздыру турында нигезләмә» сүзләрен «Торак биналарны, коммуналь һәм социаль-мәдәни билгеләнештәге объектларны реконструкцияләүне, ремонтлауны һәм техник хезмәт күрсәтүне оештыру һәм уздыру турында нигезләмә» ВСН 58-88 (б)» сүзләренә алмаштырырга;

14 бүлекнең «г» пунктының икенче абзацында «башкарма хакимият органнары» сүзләрен «җирле үзидарә органнары» сүзләренә алмаштырырга;

бүлмә милекчесе белән күпфатирлы йорт белән идарә итү шартнамәсенә 6 нчы кушымтада «(вазыйфалары, фамилияләре, исемнәре, аталары исемнәре)» сүзләрен «(вазыйфалары, фамилияләре, исемнәре, аталары исемнәре (соңгысы - булган очракта)» сүзләренә алмаштырырга;

татар тектсында бүлмә милекчесе белән күпфатирлы йорт белән идарә итү шартнамәсенә 8 нче кушымтаның 1 пунктында «2006 ел, 13 август, 491 нче» сүзләренә кадәр «Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тоту кагыйдәләрен һәм Торак урынны карап тоту өчен тиешле сыйфаттагы күпфатирлы йортта хезмәт күрсәткән һәм (яисә) билгеләнгән дәвамлылыктан артып киткән күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тоту һәм ремонтлау эшләрен башкарган очракта түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында» сүзләрен өстәргә, «2013 ел, 15 май, 416 нчы» сүзләренә кадәр «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибе турында» сүзләрен өстәргә;

әлеге карарга 5 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге карарга 6 нчы кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы дәүләт торак фонды, муниципаль торак фонды, шулай ук хосусый торак фонды составына керә торган торак урыннарга мөнәсәбәтле, инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып, инвалидларның торак урыннарын уңайлаштыру чараларын яраштыру буенча Татарстан Республикасының вәкаләтле башкарма хакимият органын билгеләү турында” 2016 ел, 20 декабрь, 958 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы дәүләт торак фонды, муниципаль торак фонды составына керүче торак урыннарга, шулай ук хосусый торак фондына инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып, инвалидларның торак урыннарын җайлаштыру чараларын мониторинглауны һәм координацияләүне гамәлгә ашыру максатларында

Министрлык адресына инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып һәм инвалидларга алардан файдалану шартларын тәэмин итү максатларында инвалидларның торак урыннарын һәм инвалидлар яшәгән күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәтне тикшерү буенча муниципаль комиссияләрнең бер елдагы эш йомгаклары турында хисаплар җибәрергә.»;

әлеге карар белән расланган Инвалидларның ихтыяҗларын һәм инвалидлар өчен файдалана алу шартларын тәэмин итүне исәпкә алып, инвалидларның торак урыннарын һәм Татарстан Республикасы торак фонды составына керә торган инвалидлар яши торган күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне уңайлаштыру буенча чаралар планын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Безнең ишегалды» республика программасын әзерләү, формалаштыру һәм тормышка ашыру буенча ведомствоара эшче төркем турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау хакында» 2019 ел, 23 ноябрь, 1071 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 20 декабрь, 1170 нче, 2020 ел, 28 гыйнвар, 45 нче, 2022 ел, 23 декабрь, 1400 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган «Безнең ишегалды» республика программасын әзерләү, формалаштыру һәм тормышка ашыру буенча ведомствоара эшче төркем турындагы нигезләмәдә:

4 пунктның дүртенче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарының» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта:

дүртенче абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «предприятиеләр» сүзен «оешмалар» сүзенә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органына» сүзләрен «республика башкарма хакимият органына» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Безнең ишегалды» республика программасын әзерләү, формалаштыру һәм тормышка ашыру буенча ведомствоара эшче төркем составында Хәмзина Лена Илдар кызы вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының Техник инвентаризация һәм кадастр эшләре бюросы» акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин